Тукай муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге Бәтке поселогы **ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

«17» ноябрь, 2020 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районы «Бәтке» авыл җирлеге уставы нигезендә

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «2021 елда яшәү урыны буенча Бәтке авыл җирлеге Бәтке поселогы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә:
- Бәтке авылында ясалма тигезсезлекләр урнаштыру
- Бәтке авылынын Үзәк урамы буенча тротуар ремонты
- Бәтке авылында яшел үсентеләр утырту һәм кисү
- Бәтке авылы территориясен чабу
- Бәтке авылында юлларны төзекләндерү
- Бәтке авылында урам утларын сатып алу һәм урнаштыру
- Бәтке авылында паркта видеокүзәтү камералары алу һәм урнаштыру
- Бәтке авылынын Жемчужная урамы буенча су белән тәэмин итү системасын ремонтлау
- Бәтке авылынын христиан зиратына материаллар сатып алу һәм часовня урнаштыру;

2. Тукай муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге Бәтке поселогы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

3. Тукай муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге Бәтке поселогы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Бәтке авыл җирлеге Башлыгы В.А.Валиева